| СОВЕТ ЛЕВАШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ЛЕВАШЕВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

16.03.2020 с. Левашево № 132

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Левашево авыл җирлегендә Бюджет корылышы һәм бюджет процессы турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

Гамәлдәге законнарга, шул исәптән «Россия Федерациясе Бюджет кодексына казначылык хезмәте күрсәтү һәм казначылык түләүләре системасына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 27 декабрендәге 479-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләренә туры китерү максатларында

**Левашево авыл җирлеге Советы карар кылды:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Левашево авыл җирлеге карары белән расланган Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Левашево авыл җирлегендә Бюджет корылышы һәм бюджет процессы турында Нигезләмәгә 2015 елның 26 гыйнварындагы 108а номерлы, түбәндәге эчтәлекле:
- 13 матдәнең 16 пунктында «акчаларны исәпкә алу буенча» сүзләрен төшереп калдырырга;
- 30 матдәнең 2 пунктындагы 2 абзасында «кассадагы» сүзен «казначылыктагы» сүзенә алмаштырырга.
2. Әлеге карарны Левашево авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Левашево авыл җирлеге советы бинасында мәгълүмат стендында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Алексеевск муниципаль районының Левашево авыл җирлеге башлыгы, Совет рәисе** **С.А.Демидова**